ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 10 февраля 2020 года** **№ 9**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының 2016 нчы елның 11 нче февраленнән 26 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге турындагы Нигезләмәсен раслау турындагы” карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 нчы елның 16 нчы декабреннән 432-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарын камилләштерү максатыннан Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турындагы” Федераль законы нигезендә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Биектау муниципаль районы Башлыгының 2016 нчы елның 11 нче февраленнән 26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы Вазыйфасы инструкцияләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче бүлекнең 3.4. пунктында:

а) 1 нче пунктчаны «төшереп калдырырга»;

б) 3 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәге очраклардан кала, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән, профессиональ союз органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән профсоюз оешмасының беренчел сайлаулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка җәмәгать оешмасының, торак, торак-төзелеш, гараж ширкәтләре, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышларында катнашу;

б) (сәяси партия белән, профессиональ союз органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән профсоюз оешмасының беренчел сайлаулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка җәмәгать оешмасының, торак, торак-төзелеш, гараж ширкәтләре, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышларында катнашудан кала) Татарстан Республика законнары белән билгеләнгән тәртиптә эш бирүче вәкиле рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук идарә оешмаларында муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә белдерергә;

г) оешма учредителе вәкаләтләрен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталы өлешләре) белән муниципаль берәмлек исеменнән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокук актлары нигезендә учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә белдерергә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

в) түбәндәге эчтәлектә 3.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1) шәхсән яки ышанычлы затлар аркылы эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә;»;

г) 5 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) вазыйфаи хәле белән бәйле рәвештә яки вазыйфаи бурычларын үтәгәндә физик яки юридик затлардан бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачуларны, ялны, транспорт чыгымнарын түләү һәм башка бүләкләүләр) кабул итәргә. Протокол чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләр муниципаль милек буларак танылалар һәм, Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы билгеләгән очраклардан тыш, акт буенча Биектау муниципаль районы Советына тапшырылалар. Протокол чара, хезмәт командировкасы яки башка рәсми чара белән бәйле рәвештә алган бүләген тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясенең норматив хокук актлары билгеләгән тәртиптә акча түләп алырга мөмкин;»;

2) 5 нче бүлекнең 6 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дисциплинар җәза куллану һәм кире алу тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт турындагы законнар белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/. хокукый мәгълүмат порталына урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны Биектау муниципаль район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Г.Кәлимуллин